Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Пыжмара авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә

Пыжмара ав. 16.01.2026

Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге башлыгының 25.12.2025 № 9 карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздырылды.

Үткәрү вакыты һәм урыны: 14.01.2026 11:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: ТР, Балтач муниципаль районы, Пыжмара авылы, С.Мөлеков ур., 19.

Катнашучылар саны: 19

Гавами тыңлауларны әзерләү чорында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кермәде.

2026 елның 14 январенда гавами тыңлаулар вакытында гавами тыңлауларда катнашучылардан искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кермәде, гражданнарның хокукларын бозу һәм аларның мәнфәгатьләрен чикләү ачыкланмады. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү инициативасы бертавыштан хупланды.

Әлеге мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны узган дип танырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чиген Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерүне максатка ярашлы дип санарга.

Әлеге бәяләмәне Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

Рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Заляев